**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

# Об отмене ограничительных мероприятий (карантина), установленных на отдельных территориях муниципального образования «Буинский муниципальный район Республики Татарстан» в связи с их неблагополучием по заболеванию бешенством животных

В связи с истечением 60 календарных дней после уничтожения последнего трупа больного восприимчивого животного и проведением противоэпизоотических и профилактических мероприятий, в соответствии со статьей $3^{1}$ Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии» **постановляю**:

1. Отменить ограничительные мероприятия (карантин), установленные в связи с неблагополучием по заболеванию бешенством животных на территории в Большефроловском сельском поселении муниципального образования «Буинский муниципальный район Республики Татарстан» радиусом 30 м от географических координат: 55,092338° северной широты и 48,367596° восточной долготы и территории радиусом 3 км от границ эпизоотического очага в Большефроловском и Черки-Кильдуразском сельских поселениях муниципального образования «Буинский муниципальный район Республики Татарстан».

2. Признать утратившим силу Указ Раиса Республики Татарстан от 15 июля 2025 года № 542 «Об установлении ограничительных мероприятий (карантина) на отдельных территориях муниципального образования «Буинский муниципальный район Республики Татарстан» в связи с их неблагополучием по заболеванию бешенством животных».

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Раис**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
17 сентября 2025 года
№ 739

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

## «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең аерым территорияләрендә хайваннар котыру авырулы булганга, аларның имин булмавы сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында

Котыру чиренә бирешүчән соңгы авыру хайванның үләксәсе юкка чыгарылган көннән 60 календарь көн узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Зур Фролово авыл җирлегенең төньяк киңлекнең 55,092338° һәм көнчыгыш озынлыкның 48,367596° географик координатларыннан 30 м радиустагы территориядә һәм «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Зур Фролово һәм Килдураз авыл җирлекләрендәге эпизоотия чыганагы чикләреннән 3 км радиустагы территориядә хайваннар котыру авырулы булганга, аларның имин булмавы сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең аерым территорияләрендә хайваннар котыру авырулы булганга, аларның имин булмавы сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2025 елның 15 июлендәге 542 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе**

**Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 17 сентябрь
№ 739